КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1106

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау хакында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче; 2015 ел, 12 февраль, 85 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы; 2018 ел, 9 ноябрь, 984 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

икенче абзацта «торак пунктта» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлешендә)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «торак пунктта» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлешендә)» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агымдагы финанс елына кадәрге елда законнар нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә (җирлек, шәһәр округы составына керә торган торак пунктта (яисә аның территориясенең бер өлешендә)) гражданнарга үзсалым кертү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарлар күчермәсен;»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасының i муниципаль берәмлеге өчен башка бюджетара трансфертлар күләме ($МТ_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

а) Татарстан Республикасының i-муниципаль районы өчен:

$$МТ_i = \sum_{j=1}^{n}(К_j \times СС_j),$$

монда:

n – заявкага кертелгән, агымдагы финанс елына кадәрге елның II – IV кварталларында һәм агымдагы финанс елның I кварталында бюджетларына агымдагы финанс елына кадәрге елда җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча кергән, Татарстан Республикасы муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасы авыл һәм шәһәр җирлекләре саны;

$К_j$ – гражданнарның үзсалым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасының j шәһәр, авыл җирлеге бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасының 1 сумына бирелә торган, түбәндәге сумнарга тигез итеп алынган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме:

4 сумга – шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм Татарстан Республикасы шәһәр җирлекләре өчен;

3 сумга – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган Татарстан Республикасы шәһәр җирлекләре (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре», Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәм-

лекләреннән тыш), Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге өчен;

2 сумга – Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре», Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлекләре өчен;

$CC_j$ – агымдагы финанс елына кадәрге елның II – IV кварталларында һәм агымдагы финанс елның I кварталында Татарстан Республикасының j шәһәр, авыл җирлеге бюджетына агымдагы финанс елына кадәрге елда җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кергән гражданнар үзсалым акчасының гомуми күләме, сум;

б) Татарстан Республикасының i шәһәр округы өчен:

$$MT_i = K \times CC_i,$$

монда:

К – гражданнарның үзсалым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасының шәһәр округы бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасының 1 сумына бирелә торган, 2 сумга тигез итеп алынган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме;

$CC_i$ – агымдагы финанс елына кадәрге елның II – IV кварталларында һәм агымдагы финанс елның I кварталында Татарстан Республикасының i шәһәр округы бюджетына агымдагы финанс елына кадәрге елда җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кергән гражданнар үзсалым акчасының гомуми күләме, сум.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасының муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органында Татарстан Республикасының муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына ачылган казначылык счетына күчерелә.»;

11 пунктта «муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле әһәмияттәге» сүзләрен «җирле әһәмияттәге» сүзләренә алмаштырырга, «торак пунктта» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлешендә)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Гражданнар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 19 ноябрь, 1106 нчы
карары редакциясендә)

Форма

Гражданнарның үзсалым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка

_______________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)

_______________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең торак пункты исеме)[1]

| Т/с | Исеме | Мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Гражданнарның үзара салым акчасын тоту юнәлешләре | х |
| 1.1. | муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләсе исеме | |
| 1.1.1. | чаралар исеме | |
| | | |
| | | |
| 1.2. | муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләсе исеме | |
| 1.1.2. | чаралар исеме | |
| | | |
| | | |
| ... | ... | |
| 2. | Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән гражданнарга үзсалым кертү турындагы карар реквизитлары | |
| 3. | Гражданнарга үзсалым кертү турындагы карар нигезендә гражданнарга үзсалым кертелгән территория (3.1 – 3.2 нче юлларның берсендә «V» тамгасын куярга яисә 3.3 нче юл буенча торак пункт территориясе өлеше исемен күрсәтергә) | |
| 3.1. | муниципаль берәмлек | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3.2. | торак пункт | |
| 3.3. | торак пункт территориясенең бер өлеше (исеме) | |
| | | |
| | | |
| 4. | Җирле референдум (гражданнар җыены) үткәрү вакытына «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 1 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекнең (торак пунктның яисә торак пункт территориясенең бер өлешенең) барлык халкы саны, барлыгы, шулардан: | |
| 4.1. | гражданнарның аерым категориясенә кертелмәгән | |
| 4.2. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 4.3. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 5. | Аерым категорияләргә кертелгән муниципаль берәмлек халкы саны өлеше, % | |
| 6. | Гражданнар өчен җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән гражданнарга үзсалым кертү турындагы карар нигезендә билгеләнгән бер тапкыр түләү күләме (сум): | |
| 6.1. | гражданнарның аерым категориясенә кертелмәгән | |
| 6.2. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 6.3. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 7. | Чараларның кыйммәте (сум), шул исәптән: | |
| 7.1. | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы (сум) | |
| 7.2. | гражданнарның үзсалым акчасы (сум), шул исәптән: | |
| 7.2.1. | гражданнарның аерым категориясенә кертелмәгән | |
| 7.2.2. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 7.2.3. | категориягә кертелгән (категориясе күрсәтелә) | |
| 8. | Җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзсалым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен муниципаль берәмлек бюджетына кергән гражданнар үзсалым акчасының гомуми күләме, барлыгы (сум), шулардан: | |
| 8.1. | агымдагы финанс елына кадәрге елның II – IV кварталларында җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзсалым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен муниципаль берәмлек бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасы күләме (сум) | |
| 8.2. | агымдагы финанс елының I кварталында җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзсалым кертү турында кабул ителгән карар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәлә- | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ләрне хәл итү өчен муниципаль берәмлек бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасы күләме (сум) | |

20____ ел, «____» _____________

Муниципаль район,
шәһәр округы башлыгы ___________________ __________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

________________________